## КАЛӘМ ОЧЫНДАГЫ ХИКМӘТЛӘР

Госман Гомәр атлы журналистны һәм язучыны күптән беләм, әсәрләрен укып барырга тырышам. Үзе белән очрашканда, бер-беребезгә якты йөз күрсәтеп, хәл-әхвәл дә белешәбез. Шунысы мөһим: ул бернәрсәгә дә битараф түгел. Г. Гомәрнең каләме әйләнә-тирәбездәге матурлык гармониясен барлыкка китерүчеләрне яклауга, аларның өстенлеген раслауга, шулар яктылыгына күләгә төшерүчеләрнең түбәнлеген күрсәтеп бирүгә юнәлтелгән. Димәк, бу капма-каршылык, бер ноктада кисешеп, бер максатка — яшәүнең кешелек кагыйдәләренә нигезләнергә тиешлеген раслауга хезмәт итә.

Дөрес, бу очракта, без әдәбият алдына ул хәл итә алмаслык бурыч куймыйбызмы, дигән сорау да туарга мөмкин. Г. Гомәр әсәрләре уңаеннан ул хакта язучы Барлас Камалов та уйланган булган: «Әдәби китаплар җәмгыятьтәге яман шешләргә каршы бердәнбер чара түгел, ләкин ул әсәрләр кешеләрнең күзен ачарга, яшәү мәгънәсе һәм кылган гамәлләребез хакында уйланырга этәрә. Җитди уйлана башлаган адәмнәрнең күпчелеге кыек юлга басмый, әшәкелек эшләүдән үз-үзен тыярга тырыша» (Казан утлары. — 1998. — № 4. — 173 б.). Г. Гомәр әсәрләре исә игелекле фикер, уй-хисләр алып килүе җәһәтеннән, татар әдәбиятының олы традицияләрен дәвам иттерә.

Чынбарлыкка тугрылык, үзе белгәнгә нык таянып язу Г. Гомәр иҗатының күркәм үзенчәлеген тәшкил итә. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел. Аның замандашларын тормыш үз агымына бик тиз һәм зур көч белән бөтереп ала. Ватан сугышы башланганда, мәсәлән, Госманга нибары 8 яшь була. Сугыш тәмамланган елны ул инде заводта фрезерчы булып эшли башлый. Агаебыз хәзер дә зур гәүдәле түгел. 12 яшьлек малай чакта әле бигрәк тә кечкенә күренгәндер. Зур-зур станокларга ничек буе җиткән дә, аларны ничек хәвеф-хәтәрсез эшләтә алды икән? Хәер, ул вакытта үз яшьләренә караганда иртәрәк кул арасына керә башлаучылар бер Госман гына булмаган. Ул еллардагы балаларның язмышы барысыныкы да бертөсле. Аның каравы 1941—1945 елларда

фидакярләрчә хезмәт иткән өчен бирелгән медальне күкрәгенә таккан мизгелне Госман Гомәр улы гомер буе күңелендә саклый. Әле ярый аңа дәүләт бүләген тылдагы хезмәте өчен бирәләр. Ә «Гармун телләре унике» әсәренең каһарманы, 13 яшьлек Гали Сафин исә, Сталинград сугышында күрсәткән батырлыгы өчен III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Калмык якларындагы ятимнәр йортында тәрбияләнүче балалар, әнә шулай корал тотып, кулдан килгәнчә, дошманга каршы көрәшергә мәҗбүр була. Шулай итеп, Г. Гомәр – станок янында, Г. Сафин фронтта Җиңүне якынайтуга үз өлешен кертә.

2013 елда Г. Гомәргә 80 яшь тулу уңаеннан Балык Бистәсендә зур әдәби-музыкаль кичә булган иде. Язучының авылдашлары, туганнары, район җитәкчеләре бик тә тыйнак, хәтта оялчан, әмма зур тормыш юлы үткән якташлары хакында бик яратып, дулкынланып, үз итеп сөйләде. Шунда бер өлкән апа әйткән сүзләр әле дә колагымда яңгырап тора сыман.

— Кеше, сүз дә юк, яшь чагында романтик табигатьле була, аны хыяллары канатландыра. Чөнки ул тормышта нинди дә булса үрләргә күтәрелүне максат итеп куя. Очучы яки инженер, галим яки каһарман, укытучы яки табиб булырмын, ди. Болар — табигый нәрсәләр. Госманыбыз да шундый хыяллар белән янды. Әмма ул, барыннан да элек, кеше булуны максат итте. Ә кеше булган кеше башка максатларына да ирешми калмый. Безнең якташыбыз да танылган журналист һәм язучы булды, — дигән иде ул.

Классик әйткәндәй, журналистлык эшендә дә Г. Гомәр «түбәннән, тормышның төбеннән» күтәрелә. Әле заводта эшләгәндә үк, гәзитләргә хәбәрләр, тора-бара мәкаләләр, очерклар яза башлый. Иҗатка тартылу аны Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә алып килә. Саба һәм Красный Бор районнары гәзитләрендә эшләү яшь журналистның каләмен тагын да үткен һәм йөгерек итә. Кама буендагы әлеге район бетерелгәч, ул республикабызның төп басмасы булган «Совет Татарстаны»на («Ватаным Татарстан») эшкә чакырыла. Озак еллар «Татарстан яшьләре» гәзитендә хезмәт куя. Соңыннан күренекле язучы Рафаэль Мостафин тарафыннан яңартылган «Татарстан» журналының бүлек мөдире итеп тәгаенләнә.

Ә менә 70 нче еллар урталарында Гомәр ага Бәширов белән булган бер сөйләшүдән соң ул әдәби иҗат белән ныклап шөгыльләнергә карар кыла.

— Карале, — ди аңа өлкән әдип, — матбугат тирәсендә бик

күптәннән чуаласың. Әмма шигырь, хикәяләреңне укыганым юк.

— Журналист ич мин, — дип җаваплый Г. Гомәр.

— Ул һөнәрең әдәбиятка комачаулыймы?

— Бер повесть яздым әле.

— Исеме ничек?

— «Гармун телләре унике».

Күрәбез: Г. Гомәр бу әсәрен шул вакытта ук иҗат итеп куйган икән. Ә ул аны 2004 елда гына китабына кертте. Димәк, әсәрнең кайсы елда басылуына карап түгел, ә аның кайчан язылуы буенча исәпләгәндә, Г. Гомәрнең әдәбиятта каләм тибрәтә башлаган вакытын шактый төгәл чамаларга мөмкин.

Беренче әсәреннән үк күренгәнчә, авторны халык язмышындагы аеруча җитди хәлләр борчыган икән. Әйтик, әле бездә Сталинград сугышы мәхшәрләрендә татар үсмерләренең кулга корал тотып көрәшүен тасвирлаган әсәр юк иде. Г. Гомәр шушы хәлләрне тетрәндергеч итеп сурәтләп бирә алды. Шулай итеп, ул сугыш чынбарлыгын дөреслеккә хилафлык китермичә бәян итү традициясен яңа чор әдәбиятыбызда дәвам иттерүгә иреште. «Гармун телләре унике» повесте аны язучы буларак раслаган әсәр булды. Аннан соң ул укучыларга «Юлбарыс тырнагы» (1992), «Шаһмиран» (1994), «Мөһер» (1996) кебек маҗаралы-детектив повестьларын тәкъдим итте, байтак хикәяләре дөнья күрде. Укучы аларны җылы кабул итте. 1999 елда каләмдәшебез Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде. Бу уңайдан академик Әбрар Кәримуллин болай дип язды: «Ярты гасыр татар журналистикасында эшләп, үзенә күрә дөнья, кешеләр тану университеты үтеп, әдәбиятыбызга килеп кергән Госман Гомәргә бу өлкәдә дә зур уңышлар телим». Татар китабы тарихын олы фән дәрәҗәсенә үстергән күренекле галимнең бу теләкләрен чынга ашыруда Г. Гомәр бар тырышлыгын һәм иҗат илһамын эшкә җигә.

Язучының үзенә генә хас тагын бер игелекле эше бар. Сүз аның замандашларына багышланган кечкенә күләмле язмалары турында бара. Әлеге кыска гына хикәя-парчалар күп кенә күренекле шәхесләрнең нинди дә булса үзенчәлекле холык-фигылен күзалларга мөмкинлек бирә. Аларны укыганнан соң, күбесен үзебез дә белгән әлеге замандашларыбызга тагын да зуррак хөрмәт белән карый башлыйсың, ә кайсыларына карата, болай икән бу дип, нindидер тискәре мөнәсәбәт тә барлыкка килә. Аларны тасвирлаганда, автор еш кына юмор, яратып көлү алым-

нарын куллана. Шуңа күрә әлеге парчалар җиңел укыла һәм хәтергә дә уелып кала. Нәтиҗәдә замандашларыбызның холык-фигыле, әйләнә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәте сурәтләнгән энциклопедия кебегрәк бер тупланма барлыкка килә. Шул ук вакытта парчаларда авторның үз образы да әһәмиятле урын тота. Димәк, бу әсәрләр аның үз шәхесен төрле шартларда ачуга да хезмәт итә. Шунысы мөһим: ул кемнәрдер кебек үзенең күренекле шәхесләр белән таныш булуын күрсәтүне үзмаксат итеп куймый, киресенчә, аларны алгы планга чыгара, үзен вакыйгаларны бәйләүче сыйфатында гына «файдалана».

Госман Гомәр кешеләр турында яратып, үз итеп яза, алар тагын да матур, камил булсын, дигән теләк белән иҗат итә.

Фоат Галимуллин,<br>әдәбият галиме

# ШӘХЕСЛӘР
# ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР